**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«01» сентябрь 2026 ел № 24

**Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 01 ноябрендәге 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 25 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 01 ноябрендәге 53 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «депутат вәкаләтләре чоры» 2 статьяның беренче өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Советының яңа чакырылыш хокуклы составтагы беренче сессиясен уздырган көннән туктатыла.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гәйтән авыл җирлеге
Советы рәисе Н.В. Авдеева